ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27 апрель 2022ел № 2214

Хезмәт урыныннан бирелә торган торак урыннарны муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан чыгару тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында

Хезмәт урыныннан бирелә торган торак урыннарны муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан чыгару тәртибен җайга салу максатында, Россия Федерациясе Торак кодексының 103 статьясы, «Россия Федерациясе Торак кодексын гамәлгә кертү турында» 2004 елның 29 декабрендәге 189-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы, шәһәр Уставының 42 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Хезмәт урыныннан бирелә торган торак урыннарны муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан чыгару тәртибен кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Хезмәт урыныннан бирелә торган торак урыннарны муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан чыгару тәртибе турында нигезләмәне раслау турында» 2010 елның 23 мартындагы 1808 номерлы;

2) «Башкарма комитетның 2010 елның 23 мартындагы 1808 номерлы карары белән расланган Хезмәт урыныннан бирелә торган торак урыннарны муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан чыгару тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 18 октябрендәге 5458 номерлы;

3) «Башкарма комитетның 2010 елның 23 мартындагы 1808 номерлы карары белән расланган Хезмәт урыныннан бирелә торган торак урыннарны муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан чыгару тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 16 мартындагы 1222 номерлы;

4) «Башкарма комитетның 2010 елның 23 мартындагы 1808 номерлы карары белән расланган Хезмәт урыныннан бирелә торган торак урыннарны

муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан чыгару тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 26 гыйнварындагы 311 номерлы.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары А.С. Ганиевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                                 Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2022 елның 27 апрелендәге
2214 номерлы карарына
кушымта

Хезмәт урыныннан бирелә торган торак урыннарны муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан чыгару тәртибе турында
нигезләмә

1. Хезмәт урыныннан бирелә торган торак урыннарны Яр Чаллы шәһәренең муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан чыгару тәртибе турында әлеге нигезләмә хезмәт урыныннан бирелә торган торак урыннарны муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан чыгару тәртибен һәм нигезләрен билгели.

2. Хезмәт урыныннан бирелә торган торак урыннарны муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан чыгару шәһәр Башкарма комитеты карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

3. Хезмәт урыныннан бирелә торган торак урыннар муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан чыгарылырга мөмкин:

1) хезмәт урыныннан бирелә торган торак урыннарны алганнан соң Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан һәм анда эшләгән чорда хезмәт урыныннан бирелә торган торак урын бирелгән оешмаларда тулы ун ел дәвамында эшләгән затларның гаризалары буенча, түбәндәге очраклардан тыш:

- гариза бирүченең һәм аның гаилә әгъзаларының Яр Чаллы шәһәре территориясендә милек хокукында торак урыннары булу;

- гариза бирүче һәм аның гаилә әгъзалары тарафыннан Яр Чаллы шәһәре территориясендә федераль һәм республика программалары кысаларында торак урыннар сатып алу;

- шәһәр оешмалары тарафыннан түләүсез муниципаль милеккә тапшырылган торак урыннарында хезмәт урыныннан бирелә торган торак урынны наемга алу шартнамәсе буенча яшәү;

2) эш стажын исәпкә алмыйча, түбәндәге категорияләрдәге гражданнарның гаризалары буенча:

- инвалидлыгы эштә гарипләнү аркасында килеп чыккан I һәм II төркем инвалидлар;

- инвалидлыгы хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле һөнәри авырулар аркасында килеп чыккан I һәм II төркем инвалидлар;

- хезмәт урыныннан торак урын бирелгән һәм вафат булган хезмәткәрнең гаилә әгъзалары;

картлык буенча пенсионерлар;

3) суд органнары карары буенча.

4. Хезмәт урыныннан бирелә торган торак урыннарны муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан чыгару турындагы мәсьәләне карап тикшерү өчен гариза бирүче Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенең торакны үстерү бүлегенә түбәндәге документларны тапшыра:

- Башкарма комитет Җитәкчесе исеменә хезмәт урыныннан бирелә торган торак урынны махсуслаштырылган торак фондыннан чыгару турында гариза;

- дәүләт органы (җирле үзидарә органы), предприятие (учреждение) җитәкчесенең анда эшләгән чорда хезмәт урыныннан торак урын бирелгән дәүләт органы (җирле үзидарә органы), предприятие (учреждение) белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торуын дәвам итүче затлар өчен юлламасы;

- тиешле рәвештә расланган хезмәт кенәгәсенең күчермәсе яки хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр кәгазьдә яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән (хезмәт бирүчедә булганда) имзаланган электрон документ рәвешендә;
- хезмәт урынынннан бирелә торган торак урыннан файдалану хокукын раслаучы документлар;
- паспортларның төп нөсхәләре һәм күчермәләре, 14 яшькә кадәрге балалар – туу турында таныклыкның төп нөсхәләре һәм күчермәләре;
- хезмәт урынынннан бирелә торган торак урында яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнарның санын раслаучы белешмәләр;
- 1999 елның 31 декабренә кадәр дәүләт теркәвен гамәлгә ашыручы дәүләт теркәве органыннан милек хокукындагы торак урыннар булмау турында белешмәләр.

5. Бүлек тапшырылган документларны тикшерүне гамәлгә ашыра һәм хезмәт урынынннан бирелә торган торак урынны махсуслаштырылган торак фондыннан чыгару турында яки хезмәт урынынннан бирелә торган торак урынны махсуслаштырылган торак фондыннан чыгарудан баш тарту турында Башкарма комитетның карарын әзерли.

6. Башкарма комитетның хезмәт урынынннан бирелә торган торак урынннны махсуслаштырылган торак фондыннан чыгару турында карары торак урынны социаль наемга алу шартнамәсе төзү өчен нигез булып тора.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И Галиева